**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

28 гыйнвар, 2022 ел №10 Урыссу ш.т.п.

Ютазы муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисен билгеләү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыру һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 07 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы, Ютазы муниципаль районы Советының 2021 елның 10 декабрендәге №90 карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Ютазы район Советына кертелгән Ютазы муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе вазифасына кандидатура турында тәкъдимне караганнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Ютазы муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе итеп Хафизова Римма Илшат кызын билгеләп куярга.
2. «Ютазы муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисен билгеләп кую турында» 2017 елның 20 гыйнварындагы 1 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин